ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 22 » май 2024 ел № 355

**2024 елның II к варталына Арча муниципаль районы буенча 1 квадрат метр торак мәйданының уртача базар бәясен раслау турында**

Арча муниципаль районында «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлык тарафыннан торакның 1 квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча («Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыкның «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2024 елның 09 апрелендәге 1967 номерлы хаты), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатыннан, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Барлык категория гражданнар өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән торак сатып алуга (төзүгә) бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгару өчен, Арча муниципаль районы буенча 2024 елның II кварталына торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен 58404 (илле сигез мең дүрт йөз дүрт) сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. М. Гатиятов